СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

5 декабрь, 1998 ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 139 (8296) Бәясе билгеләнгәнчә

Белеп торыгыз

## СӘХНӘДӘ - ЯШЬЛӘР

*Казанда 10 декабрьдән 13енә кадәр "Татарстан яшьләре" дип аталган I республика татар эстрадасы җыры бәйгесе үткәрелә.*

*Бу иҗади ярыш республика яшьләренең I сәнгать иҗаты фестивале кысаларында узачак. Аның оештыручылары - "Татарстан Балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты, "Сәләт" фонды, "Татарстан яшьләре" газетасы. Бәйгенең максаты - яшь җырчы һәм композиторларга һөнәри сәхнәгә аяк басарга ярдәм итү. Аларның иң яхшылары арасыннан вокал, оранжировка осталары билгеле булачак, иң яшь катнашучылар, иң яхшы җырчы, язучы - шагыйрь, композитор исемнәре игълан ителәчәк.*

*Татарстан яшь талантларыннан кала, ярымфиналда Мәскәү, Чиләбе, Ульяновск, Ижау, Яңавыл җырчылары да катнаша.*

## 12 ДЕКАБРЬ ШӘҺӘР КӨНЕ

### Хөрмәтле нурлатлылар!




*12 декабрь көнне ипподром мәйданында "Шәһәр көне"нә багышланган зур бәйрәм була.*

*Бәйрәмнең программасы түбәндәгечә:*

*1. Бәйрәмне тантаналы ачу.*

*2. Спорт ярышлары һәм спорт - күңел ачу уеннары.*

*3. Нурлат шәһәре призына Мәскәү, Казан, Түбән Кама, Яр Чаллы, Тольятти, Ижевск, Ульяновск, Самара шәһәрләреннән Россиянең иң көчле спортчылары катнашында кышкы трек автомобиль узышлары.*

*4. Сәүдә предприятиеләре - Нурлат район кулланучылар җәмгыяте, "Нурлатнефть" НГДУсы, тимер юл һәм урман хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, район хуҗалыклары һәм предприятиеләре кибетләре, шәхси эшмәкәрләр, җәмгать туклануы предприятиеләре сатучылары катнашында зур ярминкә.*

*Бәйрәмдә пар атларда мәйдан әйләнү мөмкинлеге булачак. Иң җитез һәм матур бизәлгән атларга урыннар билгеләнәчәк. Ярминкәдә иң мул товар белән катнашкан һәм сәүдә нокталарын матур итеп бизәп, халыкка культуралы хезмәт күрсәткән сәүдә оешмалары һәм хуҗалыкларга да махсус урыннар каралган.*

*Бәйрәм 9.00 сәгатьтә башлана.*

*11 декабрь көнне автоузышларда катнашучылар өчен контроль үтү билгеләнә.*

*Хөрмәтле нурлатлылар, кунаклар! Шәһәр көненә рәхим итегез!*

## БЕЛДЕКЛЕ ДӘ, БУЛДЫКЛЫ ДА

*Таныш булыгыз: "Лениногорск тампонаж эшләре" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятенең Нурлат филиалы шоферы Валерий Петрович Сидимиров. Байтак еллар НУРБның автотрактор цехында эшләгәннән соң күчте ул филиалга. Техник яктан грамоталы, булдыклы шофер автобус йөртүче булып эшли, коллективта үз урынын табарга өлгергән инде.*



Н.Азизов фотосы.

## САУГАНЫ КҮПМЕ ДӘ, САТКАНЫ НИКАДӘР?

***Саннарның беренче баганасы - 11 айда дәүләткә сатылган, икенчесе - савылган сөт (бер сыерга күчереп исәпләгәндә килограммнарда).***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| "Кондырча" | 4511 | 5626 | "Төрнәс" | 1988 | 2628 |
| "Дуслык" | 4364 | 5222 | "Заветы Ильича" | 1962 | 2896 |
| Синдряков исем. | 3548 | 4333 | "Игенче" | 1902 | 2473 |
| "Киекле" | 2954 | 3587 | "Чулпан" | 1840 | 2701 |
| "Сөлчә" | 2919 | 3956 | "Татарстан" | 1835 | 2557 |
| "Өмет" агрофирмасы. | 2779 | 3855 | "Таң" | 1777 | 2645 |
| Шикәр заводы ярд.хуҗ. | 2713 | 3531 | "Үрнәк" | 1709 | 2439 |
| Хафизов исем. | 2654 | 3448 | "Комбайн" | 1600 | 2137 |
| "Чирмешән" агрофирмасы | 2348 | 3185 | "Алга" | 1413 | 2175 |
| "Рассвет" | 2127 | 4002 | Нефтебаза ярд. хуҗ. | 1196 | 1925 |
| РСУ ярд. хуҗ. | 2011 | 2470 | "Петровский" кооп. | 1080 | 2015 |
| "Илюткино" - 3 | 2004 | 3117 | "Руслан" кооп. | 881 | 1595 |
| "Илюткино" - 2 | 2004 | 3093 | | | |
| М.Җәлил исем. | 1997 | 3563 | **Район буенча** | **2294** | **3143** |

Мәгариф

## ТИКШЕРҮ ДӘ, ӨЙРӘТҮ ДӘ

Ноябрь ахырында Яңа Әлмәт урта мәктәбендә район мәгариф бүлеге методист - инспекторлары чираттагы фронталь тикшерү уздырдылар. Бу тикшерү - өйрәтү максатында булып, безгә, барлык укытучыларга бик тә эчтәлекле ярдәм иде. Кимчелек - хаталарны тактлы аңлатып, уңышларыбызга сөенечләрен белдерделәр алар.

Фронталь тикшерү уздыру бик кирәкле, чөнки ул укытучыларга булган материалны барлау һәм кирәкләрен булдыру, дәресләрне педагогик таләпләр югарылыгында уздыру өстендә эзлекле рәвештә эшләргә өйрәтә, методистларыбыз белән якыннан аралашып, уку - укыту методлары, үзебезне борчыган мәсьәләләр турында уртага салып сөйләшергә мөмкинлек бирә.

Атна буена алар безнең дәресләрдә булдылар, максатларыбыз, планнарыбыз белән таныштылар, кабинетларга куелган таләпләрне аңлаттылар, укытучыларның һәрберсе белән индивидуаль әңгәмә уздырдылар.

**Ф.ГАРИФУЛЛИНА.**
**Яңа Әлмәт мәктәбе.**

*Вакытлы матбугатка язылыр чак*

## ҺӘР САНЫГЫЗ - БҮЛӘК

Мин - "Дуслык" газетасының даими укучысы. Хәер, газета килгәч бөтен гаиләбез белән укып чыгабыз. Китапханәгә килгән укучыларга да "Дуслык" газетасын тәкъдим итәм. Кызыклы материалларны, яңалыкларны бергәләп укыйбыз, фикер алышабыз. Авылым кешеләре турындагы язмаларны аерым папкага җыя барам. Район тормышы шул газетада чагыла бит инде. Газетада еш кына бик акыллы, файдалы киңәшләр дә бирәсез. Газета килми торса, бик тиз юксынабыз, нәрсәдер җитмәгән кебек тоела. Мин һәр кешегә мөрәҗәгать итеп, "Дуслык" газетасына язылыгыз, укыгыз, үкенмәссез дияр идем. Ә сезгә, газета хезмәткәрләре, бер тәкъдимем бар. Авылларда яшьләр өчен бердәнбер тәрбия учагы - мәдәният йортлары. Ләкин аларның "утлары" яшьләргә ни бирә, безнең киләчәк буын нәрсә белән шөгыльләнә? Шул максат белән "Клуб утлары" рубрикасы ачсагыз бик әйбәт булыр, мәдәният учакларының эшләре системалы рәвештә яктыртылыр иде.

**Т.МИНГӘРӘЕВА.**
**К.Мораса авылы.**

## «ДУСЛЫК» БЕЛӘН ДУС БУЛЫП КАЛЫЙК!

1999нчы елның беренче яртысы өчен газета - журналларга язылу дәвам итә. Язылып каласы иде бит. Бу сорау һәркемне борчый. Кычытканлы авылы почта бүлекчәсендә 20нче декабрьгә хәтле түләү шарты белән газета - журналларга язылу мөмкинлеге бирелде. Хезмәт хакы күренмәсә дә, әни - әбиләребезнең пенсия акчасы хисабына булса да, яраткан газеталарыбызга язылдык әле. Район көзгесе булган "Дуслык"тан аерылмыйк, иптәшләр! Районыбыз тормышындагы яңалыклар белән һәрдаим танышып барыйк! Кыскасы,"Дуслык" белән дус булып калыйк әле!

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**Кычытканлы авылы.**




## «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

## Республика сулышы

***Икътисад һәм социаль тикшеренүләр үзәге мәгълүматларына караганда, узган атнада бер кешегә яшәү өчен кирәкле минимумның күләме 474 сум булды. Шуның 280 сумы - азык - төлек чыгымы, ә 130 сумы халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәткә карый.***

Куллану бюджетының минималь хакы 30 сумга артты һәм ул хәзер 1414 сум тәшкил итә. Ашау - эчүгә тотыла торган чыгым 510 сумга, күрсәтелә торган түләүле хезмәт 312 сумга кадәр күтәрелде. Шул ук вакытта азык - төлеккә карамаган товарларга тотыла торган чыгымнар үзгәрешсез, ягъни 409 сум килеш калды.

Узган ноябрь аенда яшәү өчен кирәкле минимум 29 сумга кыйммәтләнде. Шуның 24 сумы азык - төлеккә китә. Минималь куллану бюджеты 100 сумга артты. Азык - төлек товарларына тотыла торган чыгым 82 сумга күтәрелде. Шул ук вакытта рациональ куллану бюджеты 204 сумга кыйммәтләнде.

***30 ноябрь - 1 декабрьдә Казанның Мәрҗани мәчетендә Татарстан Диния нәзарәтенең икенче пленумы булды.***

Утырышта катнашучылар нәзарәтнең беренче пленумы узганнан соңгы чордагы эшчәнлеген бәяләделәр, изге Рамазан аена хәзерлек мәсьәләсен тикшерделәр. Шулай ук мөселман оешмаларын һәм ислам уку йортларын теркәү, кабаттан теркәү белән бәйләнешле сорауларны карадылар. Чаллы шәһәрендә нәшер ителүче "Ислам нуры" газетасы редакциясе һәм аның нәшере - "Диамант" нәшрияты җитәкчелегенең әлеге басманы Татарстан Диния нәзарәте юрисдикциясе карамагына күчерү турындагы тәкъдиме кабул ителде.

**(Республика матбугатыннан.)**

# Күңел кыңгыраулары

## Бала күңелен алдама

Фикер

Гаиләләрнең күпчелегендә бала белән күңелсез хәл килеп чыкканда ата кеше ананы гаепләргә тырыша. Моның сәбәбе ачык - хатын - кызлар бала тәрбияләү мәсьәләсендә җилкәләренә тиешеннән артык бурыч йөкләгән - бакчага илтә, алып кайта, мәктәптә укучылары белән дәресләрен әзерләшә, юындыра, тукландыра һәм башкалар. Ә этиләр эштән арып кайткач, аякны - аякка куеп, телевизор каршындагы диванга ятуны кулай күрәләр. Бераз кабып та кайткан булса, гаиләдә аның өчен өстәмә уңайлыклар да булдырырга тырышыла. Бусы да, әлбәттә, ана кеше кулында.

Иртән иртүк бар кешедән алда уянып, урыныннан күтәрелгән, ашын - чәен әзерләгән, киемнәрне әзерләп куйган. Әти кеше горур басып, чистаны киенеп, тукланып чыгып китә. Ә киемнәре пычранса, ул аларны кая куясын белә, аннан аларны пөхтәләп, үтүкләп куячакларын да сиземли. Өй чиста. Тамак тук. Бала белән дә мөнәсәбәтләр начар түгел: кулына шоколад тоттырасың да - дуслар. Анасы белән бала күрмәгәндә (күргәндә дә ярый) әйткәләшеп аласың, сүгенеп тә куясың, синекен итмәсә, бала дип тормыйсың кул да күтәреп буйсындырасың. Мондый гаиләләр һәм этиләр аз түгел, минемчә. Ләкин ата кешенең шундый роле иң элек бала тәрбияләүдә, аны шәхес итүдә зур җитешсезлек булып тора. Шоколад алып кына бала күңелен яулап булмый: бу сабыйны алдый. Аның күңеле бик нечкә, бик тиз яраланырга мөмкин. Нәкъ шул кечкенә чакта күреп үскәннәр аның гомерлек юлдашына әйләнә дә.

Мин бер абзый белән танышмын. Күптән түгел аның тормыш иптәше вафат була һәм ул ике малае белән кала. Абый малайларның үзенә салкын карауларыннан зарлана, әниләренең үлемендә аны гаепләүләрен сөйли. "Әгәр дә син исереп кайтып аны кыйнамаган булсаң, юк - барга бәйләнеп йөрәген бозмаган булсаң, ул яши иде әле, яши иде!" - дип әйтә ди олы улы. Ә абый бу хәлгә хатынын, хатынының туганнарын гаепли. Балалар кечкенә чакта, имеш, ул аларны гел этисенә каршы котырткан, аны начар яктан гына күрсәткән. Ә хәзер туганнары шулай итә, янәсе. Юк, абый, юк. Алдарсың баланың сизгер күңелен. Ул барысын да үзе күреп үсә һәм һәркемгә бәясен үзе куя. Сез пычрак сүзләр яудырган хатын ул бит - аның газиз анасы.

Хәер, кайбер гаиләләрдә шуның киресе булырга мөмкин. Бераз гына "салмыш" кайткан өчен дә үзенә ишек төбен таптарга, начар сүзләрен дә ишетергә туры килә - мондый ихтыяр көче бик йомшак булган ата да балага үрнәк була алмый.

Соңында шулай да алда сөйләнелгән этиләр колагына әйтәсе килә сүзне. Гаилә учагын сүндерми саклаган хатыныгызны рәнҗетмәгез, аңа карата җылы сүзегезне, ярдәмегезне кызганмагыз. Болар бит балагыз алдында ихтирам яулар өчен кирәк. Ул дәрес әзерләгәндә бер якта хатыныгыз булса, сез икенче якка басыгыз. Бала тигезлекне шулай күрсен. Чөнки аңа әнинең дә, этинең дә яхшылары гына һәм бер дәрәҗәдә кирәк. Ихтирамлы мөнәсәбәттә үскән бала үзе дә шәфкатьле, итәгатьле шәхес булачак.

**Роза САФИНА.**
**8нче мәктәпнең татар теле укытучысы.**



Н.АЗИЗОВ фотосы.

***

*Тормыш бит ул текә кыя сыман*
*Болытларга тигән түбәсе.*
*Уйлый кеше моның түбәсенә*
*Исән - имин ничек менәсе!*
*Бәргәләнә кеше уңга - сулга*
*Табалмыйча тормыш кыйбласын.*
*Чамаламый тормыш чыбыркысын*
*Кайсы яктан китереп сугасын.*
*Егыла - тора кеше омтыла*
*Яраланган бөркет шикелле.*
*Як - ягына ава, канат кага -*
*Очып китүләре икеле.*
*Канат кирәк, басар терәк кирәк*
*Менәр өчен тормыш үрләрен.*
*Аста тирән упкын,*
*Ярны кыйный дулкын.*
*Егылмасмы кеше, түзәрме?*
*Какшамасмы көче, егәре?..*

**Мөнәвәрә УСМАНОВА.**

## «Әле ярый сез бар!»

***Югалту кайвакыт табу да китерә. Югалту ачысыннан сыгылып төшкәндә, кешеләр янәшәләренә баскан, иң авыр хәсрәтләрен бүлешкән затларга сыеналар да: “Әле ярый сез бар!” дип, ничәмә - ничә ел аралашып йөргән дусларының, танышларының тугрылыгына юлыгып, үзләре өчен кадерле һәм алыштыргысыз терәк табуларын аңлап сөенәләр. Бу табу йөрәктәге әйтеп бетермәслек тирән сыкрануны баскандай, иңнәрдәге авырлыкны киметкәндәй була. Кеше аңлый: ул ялгыз түгел, аның озын гомер юлында ышанып сыенып серен бушатыр, киңәшкә - ярдәмгә йөгерер кешесе бар икән. Нурсинә Латыйповлар гаиләсе өчен шундый кеше булды.***

Аларның дуслыгы 20 елдан артык дәвам итте. Икесе дә кара - туткыллы чибәр, зифа буйлы - сынлы, ачык йөзле бу ике хатын - кызны беренче күргән кешеләр апалы - сеңелле дип уйлый иде. Шулай апалы - сеңелле төсле яшәделәр дә алар: сүзгә килмәделәр, гайбәт йөртмәделәр, бер - берсеннән көнләшмәделәр. Хатын - кызлар дуслыгы бик тиз гаилә дуслыгы булып әверелде. Җәүһәрия яшьли ирен югалткач та бар киңәше, кайгысы - шатлыгы белән Мусиннар гаиләсенә сыеп яшәде. Ялгыз хатын ике баласын укытты, туйлар үткәрде, карт әнисен асрады, зур йорт - җирен ирләрчә барлык белән алып бару өчен көне - төне эшләде, йөгерде. Шәхси тормышын да рәтләргә омтылып карады. Кыскасы, тормыш кочагында ике бала, бер ана белән калган хатын - кыз ашыгып - колачлап яшәргә тырышты. Кешедән көнләшмәде, усаллык итмәде, ялгыз хатын язмышына тигән бар өлешне горурлык, акыл белән күтәрә белде. Аның эчендә ни янганын, нинди кыен сәгатьләр үткәрүен иң якыннары Мусиннар гына белде.

Бәла - яман чир алар гаиләсенә көтмәгәндә керде һәм мәкер, авырту белән аның көннәрен кимерә башлады. Шул караңгы чорның һәр көнендә аның янәшәсендә Нурсинә булды. Аны Казанга шифаханәгә алып баручылар да, мәрхүмәнең теләге буенча имчеләргә күрсәтүчеләр дә Мусиннар булдылар. Нурсинә пенсия кәгазьләре артыннан да йөрде, дарулар да эзләде, көннәр буе сызланган Җәүһәриянең авыртуын басар өчен ниләр генә эшләмәде ул! Тормыш туктап калган йортта Нурсинә җылы, яшәү көче бөркеп торучы бердәнбер зат иде. Юк, аның дуслары юк диясем килми, алар байтак иде һәм һәрберсе үзенчә аның хәлен җиңеләйтергә, ярдәм итәргә тырышты. Әмма көннән - көн сулып барган, гомеренең соңгы көннәрен кичерүен тоеп бар әрнүен бушатып, васыятен җиткереп калырга ашыккан кеше янәшәсендә бер генә көн булу да күпме түземлелек, сабырлык соравын үзе авыру тәрбияләгән кеше генә беләдер. Ә Нурсинә бит көннәр генә түгел, айлар буе сабырлыгын җуймады: юындырды, массажлар ясады, җаны тыгызланган чагында күтәреп урыннан - урынга күчерде... Шуңадыр, мәрхүмә бер сүзне еш кабатлый иде: "Балаларга ата - ана урынына сез каласыз. Әле ярый сез бар. Зинһар, киңәшегезне кызганмагыз, кирәк чакта терәк булыгыз, акыл - тәүфыйкларыннан чыкмасыннар". Газиз әниләрен югалтудан сулып, сыгылып төшкән балалар иң кыен вакытта да Нурсинәгә төбәлделәр. Мәрхүмәне җирләү, ашларын уздыру кебек мәшәкатьләрдә ул янә башлап йөрде. Якын дустын югалтуга күңеле әле дә ышанып җитми - ишек ачылган саен, елмаеп - балкып ул килеп керер төсле... Әмма үлем бар шул, югалту бар! Югалтуның иң ачысын кичергән балалар алдында сыгылып төшмәскә, аларга да ныклык өстәп яшәргә тырыша ул. Бирешергә ярамый. Бу бит аның - икенче гаиләсе. Мәрхүмәнең васыяте буенча, аларга әле ата - ана киңәше биреп яшисе бар бит әле аның.

Ходай сезгә игелек, көч һәм озын гомер бирсен!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**



***“Рәхмәт сезгә...”-***
***“Кичерегез мине...”-***
***Таныш иде миңа бик күптән:***
***Гали сүзләр диеп беленгәнме,***
***Тыштан гына әйтеп йөрелгәнме,-***
***Серен белми бик күп ел үткән.***
***Һәм, ниһаять, ул тылсымлы сүзләр***
***Мәгънәсенә йөрәк төшенде-***
***Бик үзгәртә икән кешене:***
***Тирә - ягым тулы ачык йөзләр,***
***Таң нурлары иңгән якты күзләр,***
***Һәммәсе дус, якын - ягымлы.***
***Искә алдым теге чагымны:***
***Тик үземне генә сөелгән бит.***
***Дөньясында барыбер яхшылык күп,***
***Дөньясында барыбер яктылык күп:***
***Күңелемдә, хисләремә үрелеп,***
***Гөлләр шытып чыкты- яшәрә...***
***Кызык булып китте яшәргә.***

***Гакил СӘГЫЙРОВ.***

## Очрашу

### (Булган хәл)

"Вокзаллар күрештерә дә, аера да",- дип тикмәгә генә әйтмиләр шул. Миңа да кечкенә уеннарда бергә йөреп, яшьлек хыялларын уртаклашкан күрше авыл егете - 42 ел буена күрешмәгән дустым белән нәкъ менә вокзалда очрашу насыйп булды. Көтмәгәндә очрашсак та, шунда ук бер - беребезне таныдык, шунда ук исемнәребезне әйтеп күрештек без. Инде икебез дә олы яшьтәге кешеләр булсак та, күзләр картаймый икән! Күздән - күзне, кулдан - кулны алалмыйча, үтеп баручы тормышларны сораша башладык. Аны каршыларга килүчеләр ашыгалар иде булса кирәк. Шулай да мин аңа ничәмә еллар буе күңелемдә йөргән соравымны бирми кала алмадым. "Хәтерләсәң, яшьлегеңдә син бер кыз белән озак кына дуслашып йөрдең, аның белән тормыш кору иң зур хыялыңа әверелгән иде дип беләм. Бик ашыксаң да әйт әле: нигә бергә була алмадыгыз?" - дим.

- Гомерлек уемда, йөрәк янында йөргән авыр ярама кагылдың, дустым. Әйдә, бәлки, мин дә гомерлек авыр йөктән арынырмын,- диде ул һәм үзен көтүчеләргә нидер әйтеп килде дә, без икебез генә бер читкәрәк барып утырдык. Дустым миңа менә ниләр сөйләде.

- Ул 8нче классны тәмамлады да, таныш кызларына ияреп, Казанда тегүчеләр әзерли торган училищега барып урнашты. Дөрес, ул мине: "Әйдә, син дә берәр яры урнаш, бергә укырбыз",- дип үгетләп карады каравын. Ләкин минем бит үз хыялым бар иде: агроном булу теләге белән яна идем. Минем унынчыны тәмамлап, авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә ниятләвемне ул да белә иде. Шуңа күрә дә ике ел гомер күп түгел, дип,



беребезне беребез көтешеп, хәбәрләшеп торырга сүз куешып аерылыштык.

Беренче елны ул авылга еш кайтты. Үзем дә берничә тапкыр Казанга бардым. Бик тә сагыныша идек шул. Икенче елны күрешүләр сирәгәйде, гел хат белән сөйләшеп тордык. Унынчыны тәмамлагач, язмыш мине Казанга түгел, Лаешка алып китте. "Ике елдан барыбер агроном булам, калганын читтән торып укырмын",- дип хыялландым. Арада хатлар йөрде, карашларыбыз, күңелләребез гел бергә иде.

Менә аның укуын тәмамлап, диплом алу көне җитте. Ул мине дә шул кичәгә Казанга чакырды. Күрешү урыны билгеле - Горький исемендәге ял паркында моңа кадәр очраша торган җирдә иде. Белсәң иде шул көнне ничек җиткерә алмаганымны! Йокы да, ашау - эчү дә бетте, көн дә, сәгатьләр дә үтмәскә әйләнде: Башымда: "Бу көнне минем язмыш хәл ителәчәк, мин аны Лаешка алып кайтып эшкә урнаштырачакмын. Шул көннән без гел бергә булачакбыз",- дигән уйдан кала берни юк иде...

Ниһаять, ул көн җитте. Билгеләнгән вакыттан әллә никадәр алда барып бастым мин очрашу урынына. Вакыт агымы бөтенләй туктап калды кебек. Утырып та карыйм, йөреп тә алам, ятып та. Йөрәкнең сикергәне колакка ишетелеп бимазалый, җиргә ятсам - җирне селкетә кебек. Менә чыр - чу килгән тавыш ягына борылсам - алар!.. Мин җирдән күтәрелеп тә өлгермәдем, иптәшләреннән аерылып, ул минем янга килеп чүгәләгән иде инде...



Дустым шушы мизгелдә сөйләвеннән туктап, дәшми генә бераз торды. Аннан янә дә сүзен дәвам итте.

- Ул килеп чүгәләүгә, минем күзләр үзләреннән - үзләре чытырдап йомылдылар да, өстемә бер чиләк салкын кое суы сипкән кебек булдым. Аннан токка эләккән кеше кебек калтырана башладым. Ник, дип бүлдермә, миңа бик авыр бу мизгелне аңлату. Чөнки ул өстенә тәнен яртылаш томаларлык та булмаган күлмәк һәм аягына үкчәле аяк киеменнән кала бүтән берни дә кимәгән иде... (Ул вакытта әле шәрә ботларын күрсәтеп йөрүче кызлар шәһәрдә дә сирәк кенә күренә, аларга да чирканып карый идек, ләбаса!..) Ә инде калын чәч толымын күкрәгенә салып йөртә торган сөйкемле җан урынына, каршымда чәч урынына мич торбасы бутый торган пумала сыман йөнтәс башлы бер зат басып тора иде. Ә битендә - нинди генә буяу сыланмаган! Салават күперенең бөтен төсләре бар иде анда... Без бит синең белән битләренә иннек - кершән сөрткән кызларны да өнәп бетерми идек, табигый матурлыкны һәммә нәрсәдән өстен күрә идек.

... Менә шул хәлдә мин авырлык белән генә җирдән күтәрелдем. Аның: "Чү, Ильяс, синә ни булды, синең йөзең качты",- дип кулыма килеп кагылганын, ә үземнең: "Юк, миңа берни дә булмады. Ә сиңа - буласы булган икән инде..." дигәнемне генә хәтерлим...

Мин шушы мизгелне гомерем буена йөрәгемдә авыр яра итеп сакладым. Кем белсен, бәлки ул андый да булмагандыр да... Ә мине шок хәлендә калдырды да, үзеннән генә түгел, дөньядан да суындырды шул... Шул хәлдән соң ни ул, ни мин бер - беребезне эзләмәдек. Укуымны тәмамлап, диплом алуга, мин чирәм җир күтәрү кампаниясенә кушылып, турыдан - туры анда киттем. Читтән торып укып югары белем алдым. Ерак Көнчыгыш районнарының берсендә авыл хуҗалыгы идарәсендә агроном булып эшләдем, гаилә кордым, 3 бала үстердек, инде хәзер пенсиягә чыктым. Хатыным үзебезнең кеше булмаса да, минем өчен, әнием өчен үтә яхшы булды, бөтен көчен безнең өчен сарыф итте. Инде әнине җирләгәнгә дә 5 ел. Ул вафат булгач, авылга кайтып, картлар - карчыклар җыеп әни рухына дога багышлатып киткән идем. Шуннан гайре бер дә кайтканым юк. Үзең аңлыйсыңдыр - кайтырга теләмәдем дә...

Аннан янә туктап торды да болай диде:

- Рәхмәт, дустым, бу соравың өчен. Беркайчан да, беркем белән дә бу хакта сөйләшкәнем юк иде. Өстемнән тау төшкәндәй җиңеләеп киттем.

Менә шундый очрашу булды ул. Тикмәгә генә әйтмәгәннәр, күрәсең: "Кеше сөйли, язмыш көлә",- дип.

**И.ШӘЙХИЕВ.**
**Зирекле авылы.**

## Вакытлы матбугатка язылыр чак

# газеталары бездә кунакта

Татар иле

Татарские края

***Газеталар язмыш тарафыннан тарихи Ватаннарыннан читтә яшәргә мәҗбүр булган татарлар өчен нәшер ителә. "Татар иле", "Татарские края" газеталарына Русия Федерациясенең барлык почта бүлекләрендә дә язылырга мөмкин. "Татар иле" газетасының индексы: 54132, ә "Татарские края"ның - 54133. "Татар иле" белән "Татарские края" - диаспора татарлары өчен республикадагы бердәнбер газета.***

## АЧЫКТАН - АЧЫК СӨЙЛӘШҮ



***1999 елның гыйнвар - июнь айларына вакытлы матбугатка язылу бара. Татарстанда "Татар иле" газетасына ярты елга язылу нибары 15 сумгына тора, ә Русия буенча чак кына кыйммәтрәк (чөнки һәрбер өлкә элемтә бүлеге үз бәясен билгели). Газета каталогы бәяләре белән чагыштырганда "Татар иле" - иң арзан басмаларның берсе.***

***Әлбәттә, газетаны бизәп кенә йөрәкләрегезгә юл табып булмас анысы. Моның өчен сезнең белән бергәләп газетаны тематик яктан төрләндерү, мавыктыргыч итү, географик яктан киңәйтү максаты тора. Татар халкы Русиядә дә, БДБда да, хәтта Америкада да татар булып кала. Ә безнең газетаны укучылар дөньяның һәр почмагында диярлек яшиләр. Шуннан чыгып "Татар иле" алдындагы бурычыбыз: газетабыз битләрендә чит ил укучысын да канәгатьләндерерлек һәм замана таләпләренә җавап бирерлек язмалар булырга тиеш.***

***Редакция һәрвакыттагыча укучыларны урындагы милли - мәдәни оешмаларның татар телен, мәдәниятен, гореф - гадәтләрен саклау юнәлешендә башкарган эшләре белән таныштырып, газетаның бүгенгесе һәм киләчәге турында бәхәс, фикер алышуга мөмкинлек бирә. Кыскасы, бергә булыйк, хөрмәтле укучы! Хәерле сәгатьтә!***

***Редакция.***

## ТУГАН ТЕЛНЕ ОНЫТУ МӨМКИНМЕ?

Татар авылында туып - үсеп, шәһәргә китеп яшәүчеләр, аларның үз балаларын үзләре теләп урыс ясаулары хакында бер гыйбрәтле мисал сөйлисем килә сезгә.

Әти белән әни, саф татар авылында гомер кичереп, җиде бала тәрбияләп үстерәләр. Аларның җидесе дә шәһәргә китеп урнашалар, унбер оныклары булып, шуларның тугызы бер сүз татарча белми. Ул оныкларның унсигез баласы бар. Арасыннан берсе ичмасам үз туган телендә сөйләшсен. Сөйләшә алмый - чөнки белми. Шулай итеп, бер татар гаиләсенең тамыры корыды, татар халкының саны унсигезгә кимеде, ә урыслар саны унсигез кешегә артты.

Уйлавымча, әгәр газетабызда шушы теманы яктырткан мәкаләләр ешрак бирелсә, бик файдалы һәм урынлы булыр иде. Мин үзем дүртенче ел инде "Татарские края" газетасының укучысы. Газетаның рус телендәгесен алуымның сәбәбе шул: теге ни русча, ни татарча белмәгән якташларга биреп укытам.

**Наил ХАФИЗОВ.**
**Түбән Варта шәһәре.**

# БӨТЕН ХИКМӘТ ТӘРБИЯДӘДЕР

"Бала чагында алган тәрбия чәч агарганчы бергә булыр. Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас",- дигән татар мәгърифәтчесе Ризаэтдин Фәхретдин. Бала тәрбиясе турында сүз йөрткәндә үз - үзебездән сорыйк әле: тәрбиялеме без? Үзеңне ничек тәрбияләргә?

Чаллы шәһәрендә нәшер ителүче "Тәрбия" гәзите бөтен Татарстанга тарала. Ул ата - аналар, әби - бабайлар, укытучылар, тәрбиячеләр ярдәмендә тәрбия сорауларына җавап эзли. Гаиләдә бала тәрбиясе, халкыбызның берничә гасыр туплаган тәрбия мирасын заманга яраклы итеп куллану, тәрбия эшендәге уңай тәҗрибә, алдынгы алимнар "Тәрбия" гәзитенең төп эчтәлеген билгели. "Шәкертнең рухында аң уяту, шуңа тырышу - иң беренче шартлардан". Мәшһүр мәгърифәтче, педагог Галимҗан Ибраһимов 20нче гасыр таләбен кыскача шулай белдергән. 21нче гасырда да тәрбия эше үзендә югары аң, иман, күркәм холык, көчле ихтыяр, саф әхлак һәм әдәп сыйфатлары тәрбияләргә омтылучы яшьләргә йөз тотачак.

Татар язучылары, әдипләренең бай рухи мирасы да милли тәрбия, саф әхлак һәм әдәп өлкәсендә зур хәзинә булып тора. "Тәрбия" гәзите яңа елдан татар язучыларының тормыш һәм иҗат юллары, педагогик карашлары, әдәби әсәрләрен укыту методикасы турында кушымталар чыгаруны да күздә тота.

***Бөтен хикмәт тәрбиядәдер. Бу хакыйкатькә инанырга теләсәгез, сезне "Тәрбия" гәзитенең укучылары, фикердәшләре, хәбәрчеләре булырга чакырабыз. Аның Татарстан каталогларындагы индексы - 54169. 1999 елның 1нче яртысына язылу хакы 12 сум.***

**Г.ВӘЛИДИ**
**"Тәрбия" гәзитенең нәшир - мөхәррире .**

## МАШИНАЛАР БАТА, КЕШЕЛӘР ҮЛӘ

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, 29 ноябрьдә кичке 9лар тирәсендә Кама елгасында Спас районының Әҗмәр авылы янында"КамАЗ - 53202" машинасы боз астына китте. Машинаның шоферы - Түбән Кама шәһәрендә яшәүче егет кабинадан сикереп чыгарга өлгерсә дә, пассажир һәлак булды.

Тикшерү күрсәткәнчә, алар Түбән Камадан балыкчыларны алырга килгән булганнар һәм ярдан 400 метр чамасы эчкә кергәннәр.

21 ноябрьдә Кама елгасының Лаеш районы Ташкирмән авылы янында Казаннан килгән "Нива" автомобиле су төбенә китте.

28 ноябрьдә Иделдә - Кама Тамагы районының Елга арты Каратай авылы янында ярдан 150 метр ераклыкта Казан кешесенең "УАЗ - 3303" машинасы боз астына китте. Хуҗасы машинадан сикереп чыгарга өлгерде.

Шул ук көнне Мишәдә дә "УАЗ" машинасы батты.

**("Шәһри Казан"нан).**

## СПОРТ СПОРТ

## ЯШЬЛӘР ЯРЫШТЫ



29 ноябрьдә Аксубай авылында кикбоксинг буенча зона ярышлары үтте. Ярышлар Ана көненә багышланды. Анда барысы өч команда катнашты, урыннар түбәндәгечә бүленде: I урын - Чистай, II - Нурлат, III - Аксубай командалары.

Безнең балалар үз үлчәү категорияләрендә әйбәт әзерлекләре, көрәш техникасы белән аерылып тордылар һәм яхшы нәтиҗәләр күрсәттеләр. Болар: Н.Ткаченко, А.Демьяненко, Р. Хәмматов, Е.Бабиков, А.Юхмальчин (ДЮКФП). Кызлар арасында О.Ендирякова барлык уеннарда да җиңеп, 1нче урынны алды.

Районда спортның бу төренең үсешенә зур игътибар бирүче ДЮКФП тренерлары А.В.Ермошкин һәм Е.С. Казаевка аерым рәхмәтебезне белдерәсе килә.

**Ф.ГАЙНУЛЛИН,**
**ДЮКФП директоры.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Кычытканлы авылында яшәүче **кадерле әниебез Ләлә Исхак кызы Хәмматвәлиевага** 7нче декабрьдә 60 яшь, энебез Илнурга 11нче декабрьдә 25 яшь тула. Чын күңелебездән сезне туган көннәрегез белән котлыйбыз, исәнлек, озын гомер, тыныч тормыш телибез.

**Гүзәл, Наил, Рифат.**

Салдакай авылында яшәүче **кадерле әниебез Миннегөл Хәлиулла кызы Камалованы** 70 яшьлек юбилее белән чын күңелебездән котлыйбыз. Шатлыкларның иң олысын, тынгы белмәс йөрәгенә сихәтлек, киләчәк көннәренең кайгы - хәсрәтсез булуын телибез.

**Балалары.**

Кадерле **бабабыз Һадый Гали улы Мусинны** туган көне белән котлыйбыз. Озын гомер, нык сәламәтлек, бәхет, шатлык телибез.

**Оныклары Марат, Ринат.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

### САТАБЫЗ

**АОГВ газ миче, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-29-03.

***

**Матур туй күлмәге, кыйммәт түгел.**
Адрес: Островский ур., 6.

***

**НГДУ ЖКХсы янында капиталь гараж.** Тел.: 5-26-02.

***

**Әйбәт хәлдәге кухня шкафлары, кыйммәт түгел.** Тел.: 2-19-60.

***

**Каравыл Тавы кирпече. Бәясе заводныкыннан түбән. Китереп бирәбез.** Тел.: 2-28-65, 5-26-19.

***

**Хатын - кыз кайры туны, киелгән, кыйммәт түгел.**
Тел: 2-14-85.

***

**ВАЗ-2101, кыйммәт түгел.** Адрес: Чапаев ур., 6-11.

***

**Шифер, арзан.** Адрес: М.Җәлил ур., 22.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Өч бүлмәле фатир. Яки өстәмә түләп ике яки бер бүлмәлегә алмаштырабыз. Тимер юлдан һәм шикәрчеләр бистәсеннән тәкъдим итмәскә.**
Адрес: Октябрьнең 60 еллыгы ур., 21-4, тел.: 2-26-64.

***

**Арбасы белән ВАЗ - 2101, кузовы һәм двигателе 1997 елда капиталь ремонт үткән. Яки әрҗәле УАЗ-452гә алмаштырабыз.** Чирмешән районы, Сосновка поселогында В.Н.Дютинга мөрәҗәгать итәргә.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**"Елена" (кием - салым базары), "Альянс" (универмаг) кибетләре "Стинол", "Норд", "Юрюзань" суыткычлары сата. Ике елга гарантия, өстәмә түләүсез китереп бирәбез. Йөкләрегезне КамАЗ, ГАЗ автомашиналарында ташыйбыз.**
Б - 621 таныклыгы. Тел.: 5-41-19.

***

**Александр Николаевич Киселев исеменә документлар (шофер таныклыгы, техпаспорт) табучының бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүен сорыйбыз.**
Адрес: Төрнәс авылы.

***

**Гаиләгә (мәскәүлеләр) яшәп тору өчен (озак вакытка) өч бүлмәле фатир кирәк. АТП ягында, шәһәр үзәгендә булса әйбәтрәк.** Тел.: 2-19-84.

***

**Кер юу машиналарын өйгә килеп ремонтлау.**
Тел.: 2-28-65, 5-26-19.

***Ситдыйковның шәхси стоматология кабинеты.***

**Тешләрне дәвалау, протез кую, алтын белән йөгертү. Тиз, сыйфатлы, гарантияле.**

Язылу өчен тел.: 5-33-89. Сезне Гыйматдинов ур., 112 адресы буенча көтәбез. АА 0342 номерлы лицензия.

Нурлат кулланучылар җәмгыяте идарәсе **әнисе** үлү сәбәпле райпоның баш бухгалтеры Бүләк Габделхак кызы Кузьминаның авыр кайгысын уртаклаша.


МӨХӘРРИР С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА

**Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4654